## 5. Йөзем кызлары

Бөтенесе дә ярата
Йөзем җимешен
Әнә шуңа йөзем инде
Безнең дә исем.
Кушымта: Эй,дусларым,
Нинди рәхәт
Бергә җырлавы.
Кул чабыгыз, каршыгызда -
Йөзем кызлары!
Барыбыз да җимеш кебек
Нинди матур без
Рәхәтләнеп, бергәләшеп
Тату яшибез!
Кушымта.
Җырларыбыз җимештән дә тәмле тоелсын
Бырыгыз да безнең кебек
Бәхетле булсын!